БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«07» 05 2026 ел

**КАРАР**

№ 177

Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелешенең тышкы күренешен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын кушымтада бирелгәнчә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2021 елның 6 августындагы 232 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов